Минзәлә гимназиясе укучылары газетасы

# ЯШЬЛЕК

Декабрь 2025

## Бу санда:

2 - 4 битләр – Яңа ел бәйрәме турында

5 бит – “Безнең йолдыз” рубрикасы

6-8 битләр – гимназия яңалыклары

**Кадерле укучылар, хөрмәтле укытучылар һәм ата-аналар, гимназиябездә эшләүче барлык хезмәткәрләр!**



Сезне чын күңелдән Яңа ел бәйрәме белән тәбрик итәм! Сез – безнең киләчәгебез, өметебез һәм горурлыгыбыз. Сезнең һәрберегезнең белемгә омтылышы, тырышлыгы һәм таланты гимназиябезнең данын арттыра. Укучыларыбызга укуыгызда зур уңышлар, яңа ачышлар, иҗади илһам һәм ныклы сәламәтлек телим. Тормышыгызда кызыклы вакыйгалар, чын дуслар һәм якты җиңүләр күп булсын! Гимназиябез – һәрберебез өчен икенче йорт, белем һәм тәрбия учагы. Ул безгә уңышларга юл ача, якты киләчәккә ышаныч бирә. Бу уңышлар – укытучыларыбызның фидакарь хезмәте, ата-аналарның кайгыртуы һәм, әлбәттә, укучыларыбызның тырышлыгы нәтиҗәсе. Киләчәктә дә бердәм булып, яңа үрләр яулап, гимназиябезнең данын яңадан-яңа казанышлар белән арттырыйк.

*Ихтирам һәм олы хөрмәт белән, Гимназия директоры Галиева Лилия Альберт кызы*



Районнан 23 укучы Казанга рәис елкасына чакыру алды. Алар арасында гимназиядән 5 укучы бар иде. Республика олимпиадасында призер булган, К.Шигапова, К.Галиева, гимназия активисты Р.Хуҗәтов, йөзү буенча спорт мастеры кандидаты З.Набиева, “Сәләт-Минзәлә” клубы рәисе Я.Галиева “Татнефть Аренада”, алдынгы укучылар өчен оештырылган, бәйрәм тамашасында булып кайттылар.

# *Яңа елны кайсы илдә ничек каршылыйлар?*

Һәр бәйрәмнең үзенә генә хас гореф-гадәтләре, традицияләре бар. Яңа елны да һәр ил үзенчә каршылый. Шунысы бар: бәйрәмнең ничек, кайда, кем белән үтүе алай ук мөһим түгел, бары ел бәхет-шатлыкларга бай булсын! Россиядә Яңа елны бизәлгән чыршы, төрле утлар һәм мандарин исеннән башка күз алдына китерүе кыен. Ә менә башка илләрдә Яңа елны ничек бәйрәм итәләр икән?

**Великобританиядә** Иске елны озату һәм Яңа елны каршы алу йолалары бар. Яңа ел алдыннан төнлә бу ил халкы өйләренең арткы ишекләрен ачып куя. Бу иске ел чыгып китсен өчен эшләнә. Сәгать төнге уникене суккач, өйнең алгы ишеге ачыла. Шулай итеп Яңа елны каршы алалар.

**Шотландиядә** Иске елны «яндыру» йоласы башкарыла. Кайнар сумала тутырылган мичкәне урам буйлап тәгәрәтеп җибәрәләр. Бу урамны иске елдан «чистарту» өчен эшләнә.

**Ирландиядә** яшәүчеләр Яңа ел алды чорында аеруча да кунакчыл була. Һәрбер гаилә үз өенең ишеген ачып куя. Шулай итеп, теләгән һәркем кереп, кунак булып чыга ала.

**Болгариядә** Яңа елга аяк басарга өч минут калгач өйләрдәге ут сүндерелә. Бу өч минутны үбешүләргә багышлыйлар. Италиядә иске елның соңгы минутларында ватык савыт-сабаларны, киемнәр һәм хәтта яраксыз җиһазларны ташлау кабул ителгән. Алар иске әйберләрне ташласаң, яңаны алырсың дип ышаналар. Ә балалар исә Бефана исемле тылсымчыны көтәләр. Ул төнлә себеркегә утырып очып килә һәм, морҗа аша өйгә кереп, камин янына тезелгән балалар ботинкаларына бүләкләр салып китә, ди.

**Бразилиядә** Яңа ел һава торышына бәйле рәвештә үтә. Анда яшәүчеләр комлы пляжга меңләгән шәм тезә. Хатын-кызлар диңгезгә чәчәк таҗы, яфраклар сибә.

**Кубада** яшәүчеләр Яңа елны бер бокал чиста су белән каршы ала. Ләкин алар аны эчмиләр, ә төнлә тәрәзәдән урамга түгәләр. Болай эшләү шатлык китерәчәк дип ышана алар.

**Эквадорда** Яңа ел алдыннан иске ел карачкысын яндыру йоласы башкарыла. Карачкы иске киемнәр һәм саламнан ясала. Салам арасында узган елның начар вакыйгалары язылган кәгазь дә кыстырыла.

**Кытайда** исә Яңа ел – иң зур бәйрәмнәрнең берсе. Кытай халкы бәйрәмне календарьга бәйле рәвештә январьда яисә февральдә үткәрә. Гаилә бәйрәме булганга, теләсә кайда күңел ачу килешми. Гаиләң белән урамда йөрү матур традицияләрнең берсе. Урамда меңләгән фонарьләр эленә.

**Индиядә** Яңа ел 8 тапкыр үткәрелә. Бу ил үз җирлегендә берничә мәдәни-дини йоланы берләштерә. Шуңа күрә, төбәкләрнең гореф-гадәтләре буенча, Яңа елны теләсә кайчан үткәрәләр. Шулай да Индиядә Яңа елны язын үткәрү традиция санала. Гуди Падва дип аталган шундый көннәрнең берсендә һиндстанлылар ним-ним агачының яфракларын ашыйлар. Ул яфраклар бик ачы һәм тәмсез була. Ләкин һиндлар бу яфракларның аларны кайгы-хәсрәтләрдән һәм төрле авырулардан саклап калуына ышаналар.

**Венгриядә** Яңа елның беренче минутларында уенчык сыбызгылар белән сызгыра башлыйлар. Шулай итеп Венгрия халкы явыз рухларны өйләреннән куа, ә шатлык китерүче ияләрне чакыра икән.

**Германиядә** сәгать суга башлауга төрле яшьтәге кешеләр урындык-кәнәфиләргә һәм хәтта өстәлләргә менеп басалар икән. Ә сәгать соңгы – 12 нче тапкыр суккач, көлә-көлә идәнгә – Яңа елга сикереп төшәләр.

**Испаниядә** Яңа елда виноград ашыйлар икән. Ашалган виноград җимешләре төгәл 12 булырга тиеш. Шулай итсәң, елның 12 ае да бәхетле булачак, имеш.

**Япониядә** Яңа елны яңа киемдә каршылау традициясе яши. Японнар яңа кием уңыш һәм сәламәтлек алып килә дип саныйлар. Ә балалар Яңа ел төнендә хыялларын рәсемгә төшерәләр һәм мендәр астына куеп йоклыйлар. Болай итсәң, хыял, һичшиксез, чынга ашачак дип уйлый алар.

# *Яңа ел- сезнең өчен нәрсә ул?*



**Яңа ел белән!!!**

Яңа ел җитте! Яңа ел!
Кышы, Язы, Җәе, Көзе –
Барысы белән дә яңа ул.
Ә иске ел ерак китте.
Киткән чакта елап китте.
– Ул соңниләр алып китте,
Һәм ниләр калдырып китте?
– Фәндә, көндә яңалыклар,
Яңа бәхет, яңа йортлар,
Көне-төне янган утлар,
Гөлбакчалар, яңа җырлар
Китерде ул, һәрбер көне
Бизәп үтте туган илне –
Ил күгендә мәңге балкыр
Йолдызлар яндырып китте,
Нык сакларга кушып, безгә
Җирне, Кояшны, Дөньяны –
Барысын да калдырып китте...
Үзен генә алып китте,
Яңа ел! Яңа ел җитте!

*Рәдиф Гатауллин*

**ЯҢА ЕЛ- сезнең өчен нәрсә ул?**

**Яңа ел** - ул могҗиза. Бер яктан карасаң, ул - шундый рәхәт һәм шундый матур бәйрәм. Икенчедән, вакыт бик тиз үтә һәм без үсәбез.

Яңа ел минем өчен ул - гади генә бәйрәм түгел, ә яңа башлангычлар, яңа өметләр. Бу көнне без үзебезнең гаилә белән бергә җыелабыз. Күңелле мизгелләр башлана: яңа елны каршы алырга әзерләнәбез.

Яңа ел ул - тынычлык, мәхәббәт һәм татулык. Бу вакытта мин үземнең үткән елда булган уңышларымны, хаталарымны уйлыйм, киләчәккә планнар төзим. Яңа ел ул - үз-үзеңне яңарту һәм тормышта яңа уңышларга ирешү өчен стимул. ***Самира***

*****

**Яңа ел** ул-минем иң яраткан көнем. Бу бәйрәмгә безгә якын туганнар килә. Бәйрәм хөрмәтенә төрле тәмле ризыклар пешерәбез, өйне бизибез. Җыелып, яңа ел концертына барабыз. Әлбәттә инде, яңа ел салютын да карыйбыз. ***Аяз***

*****

**Яңа ел**- һәркем өчен дә тылсымлы, иң көтеп алынган бәйрәм. Без бәләкәй чакта яңа ел өметләр һәм шатлыклар алып килә иде. Күпме вакыт үтсә дә, бу һаман шулай икән, берни дә үзгәрмәгән. Бу бәйрәмдә без, әлбәттә, гаиләбез белән бергә булырга тырышабыз. Бездә шундый традиция бар: эти безнең барыбызны да үзенең “снегоход”ына утыртып, безне ераклардан уратып алып килә. Безгә рәхәт, сөенәбез. Яңа ел, минем өчен –шатлыклы мизгелләр һәм гаиләбезнең бергә җыелуы. ***Ралина***

*****

**Яңа ел бәйрәме** - һәр кеше өчен кадерле бәйрәмдер ул. Яңа ел сүзен ишетүгә, минем күз алдыма, матур итеп бизәлгән чыршы, мандариннар, яңа ел фильмнары, кешеләрнең елмаюлы йөзләре, яңа ел салюты, кыш бабай һәм кар кызы килә. Яңа ел - ул гаилә бәйрәме. Барлык туганнар бергә җыелып, киләсе елга яңа, матур теләкләр теләү дә бездә гадәткә кергән инде. ***Инсаф***

*****

**Яңа ел** ул- минем иң яраткан бәйрәмем. Мин аны түземсезлек белән көтеп алам. Бу вакытта чын кыш башлана: бөтен табигать ап-ак карга күмелә. Рәхәтләнеп, шыгырдатып, ак кар өстеннән атлыйсың. Киләчәктә яңа планнар корырга, дусларга матур теләкләр теләргә дә онытмыйбыз инде. Рәхәт вакыт!!! ***Илфар***

*****

**Яңа елны** каршы алу - бик үзенчәлекле ул. Бу төнне беркем дә йокламый. Иске ел узып, яңа ел башлануы ул - саннар алмашуы гына түгел, ә туганнарыбыз, дусларыбыз белән җыелуга сәбәптер. Иң бәхетле вакыт - гаилә белән җыелу. Мин туганнарыма ныклы сәламәтлек, ак кардай бәхетләр һәм илебездә тынычлык булуын телим**. *Рөстәм***

*****

**Яңа ел**-безнең өчен иң кадерле, иң күңелле бәйрәм ул. Ләкин һәркем бу бәйрәмне үзенчә кабул итә һәм үзенчә каршы ала. Кемдер аның мәгънәсен эзли, кемдер күңелен күтәрү турында уйлана. Минем өчен бу бәйрәм зур роль башкара. Мин бу бәйрәмне көтеп алам. Миңа бу бәйрәм бик ошый, чөнки без гаилә белән күрешәбез. Мине яңа елның атмосферасы сөендерә. ***Алина***

*****

**Яңа ел** ул-могҗиза. Һәр кеше бу бәйрәмне бик көтеп ала. Без бу бәйрәмне гаилә белән бергә үткәрергә тырышабыз. Яңа ел чыршысын бизибез, бергәләп яңа ел өстәлен әзерлибез. Гаилә белән шәһәр чыршысына да барып кайтабыз. Төнге 12 тулуны бик көтәбез, чөнки чыршы астыннан яңа ел бүләкләрен алабыз. Мин яңа ел бәйрәмен бик көтеп алам. Минем өчен бу - бик үзенчәлекле бәйрәм. ***Салават***

*****

**Яңа ел** - минем иң яраткан бәйрәм. Балачагымда без әниләр белән клубка чыга идек, ә кайткач, чыршы төбеннән бүләк эзли идек. Мин, чыннан да, кыш бабайга ышана идем. Үсә төшкәч кенә, әтинең кыш бабай булып киенеп, безне сөендергәнен аңладым. Шулай булса да, мин могҗизага ышанудан туктамадым. Ел саен яңа ел чыршысын да, өйне дә бизибез. Чыршы каршысына өстәл куеп, тәмле ризыклар пешерәбез. Барыбыз бергә җыелып, яңа елны каршылыйбыз. Ә инде кышкы каникулларда, Чаллы чыршысын карарга да өлгерәбез. Вакыт күңелле, ләкин бик тиз үтә. Яңа ел бәйрәме минем тормышта аерым, бик әһәмиятле урын алып тора. Яратам яңа елны. ***Зарина***

*****

**Яңа ел** - минем өчен аерым могҗиза тудыручы бәйрәм. Яңа елны каршы алыр алдыннан, кибетләрдә озын-озын чиратлар барлыкка килә. Кемнәрдер күпләп мандарин, җиләк-җимеш, яшелчә ала. Ә кемнәрдер кыздырыр өчен тавык, үрдәк эзли. Өйдә дә, кырмыскалар кебек, туган-тумача кайнаша. Мул итеп өстәл әзерлибез, чыршысын да бизибез, бер-беребезгә матур теләкләр теләргә дә онытмыйбыз. Әлбәттә инде, бәйрәм бүләксез дә булмый. Әти белән әнигә эштән бүләкләр бирәләр иде. Шуларны тизрәк ачып карыйсы килә иде бит. Яңа ел сәгате суккач, күршеләрне башта башкорт вакыты белән, яңадан Рәсәй вакыты белән котлап, матур теләкләребезне җиткерә идек. Яңа елны бергә җыелып каршы алу – үзе бер тылсымлы могҗиза. Дуслар белән урамда йөрү, рәхәтләнеп чана шуу, саф һава сулау- болар барысы да күңелгә рәхәтлек бирә. ***Ильдан***

*********

**Чыршы әйләнәсендә.**

Каршылыйк, дуслар, бергәләп:
Яңа ел килә безгә!
Әнә күпме кунак килгән
Әйләнә-тирәбезгә.
Яңа елның бәхетле ел
Буласын без беләбез.
Шуңа күрә бергәләшеп
Яңа елга керәбез!
Йолдызлар төшеп кушылган
Чыршыдагы утларга.
Кыш бабай белән Кар кызы
килгән безне котларга.

*Роберт Миңнуллин.*



# Безнең йолдыз






**Кыскача мәгълүмат:**
**Исеме:** Нәбиева Зөләйха Әнәс кызы
**Туган көне:** 22 нче апрель
**Шөгыльләре:** йөзүдән кала, йөгерү һәм чаңгыда шуу белән шөгыльләнәм.

- **Син кайда, нинди гаиләдә тудың?**
Мин Минзәлә шәһәрендә ике балалы гаиләдә тудым. Абыем Зөлфәт тә гимназиядә укыды, йөзү белән яшьтән үк шөгылләнде. Татарстан шәһәрләреннән тыш, Йошкар–Ола, Башкортстан районнарында узган ярышларда җиңүче булды. 2015 елдан “Спорт мастеры кандидаты” исемен алды. Гимназияне тәмамлагач, 2016 нчы елда “Физкультура һәм спорт” университетына укырга керде. Шул ук вакытта Чаллының фитнес клубында йөзү буенча тренер да булып эшләде. Абыемның уңышларын күреп үскәнгәдер инде, миңа да йөзү белән шөгыльләнү ошый.
- **Ничә яшьтән йөзү белән шөгыльләнәсең?**
Миңа 7 яшь булганда (2018 нчы елдан) әнием мине йөзү түгәрәгенә бирергә уйлады. Әлбәттә инде, мин каршы килмәдем. Яңадан минем үземә дә йөзү белән шөгыльләнү бик ошап китте. Бер ел йөргәннән соң, мине ярышларда катнаштыра башладылар. Мин бүгенге көндә әти-әниемә бик рәхмәтле. Әле ярый вакытында йөзү түгәрәгенә биргәннәр. Күпме шәһәрләрдә булдым, күпме дуслар таптым һәм әле алда, алла боерса, яулыйсы үрләр бик күп.
**-Тренерың белән дә таныштырып үт инде?**
Сафиуллин Алфир Гыйздуллович һәм Бәдриев Флүс Рәис улы белән шөгыльләнәм. Тренерларым бик житди. Тренировкаларга көн саен йөрим һәм шөгыльләнү күп вакытымны ала Иртән биштә торып та барырга туры килә. Шулай булмаса, уңышка ирешеп булмый.
- **Нинди ярышларда катнашканың бар?**
Башта район турында катнашсам, соңыннан инде төбәкара, республика ярышларында катнашырга туры килде. Мин Яр Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Казан, Саранск, Санк-Петербург шәһәрләрендә үткән ярышларда катнаштым. 2025 ел нәтиҗәләре буенча миңа “Спорт мастеры кандидаты” диган исем бирделәр.
- **Соңгы ярышлар кайда булды һәм ничек узды?**
Күптән түгел Россия җыелма командасы составына кердем, егетләр һәм кызлар арасында "Россия резервы" Бөтенроссия ярышларында катнаштым. Ул ярышлар 29 ноябрьдән 3 декабрьгә кадәр Саранск шәһәрендә узды. 11сентябрьдән 13 нче сентябрьдә йөзү буенча булган Татарстан чемпионатында да катнаштым. Медаль, диплом һәм грамоталарым бик күп.

**-Киләчәккә планнарың нинди?**



Гимназияне уңышлы тәмамлап, теш табибы белгечлеге буенча укырга керергә телим. Шулай да, йөзүне ташларга исәбем юк. Укып чыгып, эшкә урнашкач, киләчәктә минем тренер булып та эшлисем килә. Планнарым зурдан. Туганнарым, якыннарым ярдәме белән барысы да уңышлы булыр дип ышанам.



# Гимназия сулышы

### “Иң яхшы сыйныф җитәкчесе” конкурсы




8 декабрьдә республиканың 2025 елның “Иң яхшы сыйныф җитәкчесе”нә “Кешене тәрбияләү” исемендәге конкурсның муниципаль этабы узды.
Минзәлә муниципаль районының иң ачык, харизмалы һәм талантлы сыйныф җитәкчеләре үзләренең осталыкларын күрсәттеләр. Район мәктәпләреннән барлыгы 13 сыйныф җитәкчесе катнашты. Конкурсантлар шәхси чыгыш ясады, визит карточкасын күрсәтте һәм мастер-классларда үзләренең эш тәҗрибәләре белән уртаклаштылар. Барлык конкурс нәтиҗәләре буенча, гимназиянең беренче сыйныфлар укытучысы Гимадиева Рүзилә Рәүфәт кызы өченче призлы урынга лаек булды. Конкурс турында укытучыбызга берничә сорау бирергә булдык.

- **Конкурска әзерләнгәндә нинди кыенлыклар булды?**

Беренче сыйныфлар белән эшләү күп вакытны ала. Алар әле кечкенә, барысына да өйрәнеп кенә киләләр, тырышалар. Аларга һәрвакыт ярдәм итәргә, булышырга туры килә. Дөресен генә әйткәндә, барысына да өлгерергә кирәк, ә вакыт җитми. Конкурска да тиз арада әзерләнергә туры килде инде.

- **Район турына әзерләнү җитдилек, төгәллек сорый. Вакытында ярдәм итүчеләр, киңәш бирүчеләр дә кирәк була. Кемнәр белән берлектә әзерләндегез?**

Заман таләпләренә туры китереп, тиешенчә чыгыш ясыйм дисәң, киңәшсез, ярдәмсез район дәрәҗәсендәге конкурс- бәйгеләрдә катнашып булмый. Әлбәттә инде, беренче сыйныф укучыларымның ата-аналар коллективы зур булышлык инде. Аларга мин чын күңелдән рәхмәтле. Хәзер бит информацион технологияләр көннән-көн үсә. Шуңа күрә яңа технологияләр гамәлгә керә. Минем бер укучымның гаиләсендә “акыллы глобус” бар. Шул глобус ярдәмендә укучыларым белән эшли өйрәндек. Чөнки мастер –класста нинди дә булса яңалык белән бүлешергә, тәҗрибәң белән уртаклашырга кирәк. Менә шул вакытта миңа ярдәмгә шул “акыллы глобус” килде инде. Мин мастер класска тема сайлаганда, беренче сыйныфта сыйныф җитәкчесе буларак, үземне борчыган мәсьәләләргә тукталырга булдым. Теманы да “Ул түгел, ә - безнеке” дип алдым. Сыйныфка килгән яңа укучы (башка милләттән) белән эшләгәндә, нинди эш алымнары, нинди методика һәм нинди аралашу чаралары куллануымның нәтиҗәсе турында сөйләдем. Яңа укучыны “безнеке” дип укучыларым сыйныфка кабул итте, дус, тату яшибез.

- **Конкурста нинди темага чыгыш ясадыгыз?**

“Балалар һәм ата-аналар мөнәсәбәтләрен корганда педагогның роле” темасына чыгыш ясадым. Чыгышым бик уңышлы булды.

- **Визит карточкасы турында да берничә сүз әйтсәгез иде...**

Визит карточкасы – синең йөзең инде ул. Аңа әзерләнгәндә ясалма фәһемгә, “акыллы колонка”га мөрәҗәгать итәргә туры килде. Минем балачак фотографияләремнән башлап, бүгенге көнгә кадәр булган тормышыма багышлап видео ясадык. Укытучы булып 33 ел эшлим.

**Без сезне чын күңелдән котлыйбыз! Киләчәктә дә уңышлар юлдаш булсын!** *Сәхифәне Нәргизә әзерләде.*

# Республика семинары



18 нче декабрьдә гимназиядә татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен "Сәләтле балалар белән эшне оештыруның яңа формаларын өйрәнү һәм кулланышка кертү, комплекслы системасын булдыру" темасына республика семинары узды.

Семинарны тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Миләүшә Рәмзил кызы Хусайнова һәм тәрбия эшләре буенча директор киңәшчесе Диләрә Наил кызы Федотова алып бардылар.





Кунакларны Гимназия директоры сәламләде һәм “Укучыларның мәдәни үзенчәлеге һәм социаль-психологик иминлек факторы буларак туган телләрне саклау” турында гимназия эшчәнлеге белән таныштырды.


Семинарга килүчеләр, укучылар белән бергә, төрле кул эшләренә багышланган мастер-классларда катнаштылар. Үзләренә бүләккә ат елына багышланган яңа ел фигураларын бизәделәр, төсле ташлардан йөзек, алкалар, кар бөртекләре ясадылар. Семинарда районыбызның төрле мәктәпләреннән 8 укытучысы мастер- класс күрсәтте.

Семинар гимназия укытучылары һәм укучыларының татар теле укытучысына багышланган театр күренеше белән башланып китте һәм Айрат Шамсның "Үзем кайтмасам, хатым кайтып җитәр" исемле сәхнәләштерелгән күренеше белән тәмамланды.

Ассоциация җитәкчесе Фәттахова Рузилә Фердәвис кызы телемост аша килгән кунакларны “Укучыларны татар теленнән



олимпиадага әзерләү үзенчәлекләре” белән таныштырды.




КФУ доценты Мөгътәсимова Гөлназ Ринат кызы телемост аша “Сәләтле балалар белән эшләүдә цифрлы технологияләр” темасына чыгыш ясады.



Семинарга килгән укытучылар, үзләренең эшендә куллану өчен бик күп кирәкле һәм файдалы мәгълүмат алып киттеләр.



## “Аулак өй-көрәш”



Гимназия бинасында татар фольклорына багышланган “Аулак өй-көрәш” бәйгесе үтте. Бәйгедә 4 команда көч сынашты. “Дуслык” (4 авыл мәктәпләреннән торган җыелма команда), гимназия командасы “Яшьлек”, Тәкермән мәктәбе командасы “Калфак”, Татар Мөшегесе командасы “Чулпылар” иҗади номерлар белән чыгыш ясадылар, йола күрсәттеләр, татар әдәбияты өлкәсендә белемнәрен тикшерделәр. Район данын Арча районы Яңа Кырлай авылында узачак финалда “Чулпылар” (Татар Мөшегесе) һәм “Яшьлек” (гимназия) командалары яклаячак.

Бәйгене ТР журналистлар берлеге әгъзасы, “Аулак өй-көрәш” проекты җитәкчесе Сәрия Минеәхәтовна Зиганшина алып барды.

*****

## Сәләтле укучыларны бәйрәмчә бүләкләү!

Безнең гимназиядә Яңа ел әкияте дәвам итә! Бездә үзенчәлекле вакыйга — район олимпиадалары этабында җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү тантанасы булды. Гимназия директоры Лилия Альберт кызы Галиева яшь интеллектуальларны шәхсән үзе котлады. Бәйрәм рухындагы казанышлары өчен чын күңелдән рәхмәт белдерде, укучыларның тырыш хезмәтен һәм максатчанлыгын билгеләп үтте һәм акчалата бүләкләр тапшырды. Әкият кунаклары - Кыш Бабай һәм Кар кызы - олимпиадада катнашучылар өчен аерым кәеф тудырды. Тылсымчылар балаларны уңышлары белән котладылар һәм аларга яңа ел могҗизасының бер өлешен бүләк иттеләр. Чарада катнашучы һәркем үзен чын герой итеп хис итте, аның тырышлыгы һәм уңышлары лаеклы бәяләнде.



Без талантлы укучыларыбызның казанышлары белән горурланабыз! Бу бәйрәм киләсе елда яңа җиңүләр, казанышлар өчен тагын бер этәргеч булыр һәм җиңүчеләребез күбрәк булыр дип өметләнеп калабыз.

*****





КФУның Алабуга институты (филиалы) гомуми белем бирү учреждениеләренең IX-XI сыйныф укучылары өчен татар теле һәм әдәбиятыннан төбәк олимпиадасы үткәрде. Олимпиада ике турда узды - читтән торып (сайлап алу) һәм көндезге тур. Гимназиядән 9 класс укучысы Г.Тимергазина (җитәкчесе Заһриева Г.Р.) һәм 10 класс укучысы К. Галиева (җитәкчесе Галиева Л. А.) катнаштылар һәм Алабуга институтына көндезге турга чакыру алдылар. Олимпиаданың икенче турында барлыгы 53 укучы катнашты. Безнең укучыларыбыз җиңү яуладылар һәм I дәрәҗә диплом белән бүләкләнде. Чын күңелдән котлыйбыз, киләчәктә дә зур уңышлар телибез!